**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карары**

**2019 елның 20 декабре** **144 номерлы**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»гы 2019 елның 22 ноябрендәге 137 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Региональ салымнар буенча недоимканы, пеняларны һәм штрафларны түләтүгә өметсез дип тану өчен өстәмә нигезләр билгеләү турында» 2017 елның 19 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы һәм җирле салымнар һәм җыемнар буенча түләттерү реаль булмаган бурычларны тълщттерънe җайга салу максатларында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы  поселогы» муниципаль берәмлеге Советының « Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»гы 2019 елның 22 ноябрендәге 137 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) "Башкарма производство турында" 2007 елның 2 октябрендәге 229 - ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма җитештерүне тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан карар чыгарылуга бәйле рәвештә башкарма документлар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны мәҗбүри түләттерү мөмкинлеге булмау»;

карарның 1 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) үлгәннәрнең яки вафат булган дип танылган кешеләрнең пенялары һәм штрафлары буенча бурычлары, варисларның мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас алмаган очракта, мирас ачылганнан соң өч ел дәвамында Россия Федерациясе Гражданлык-процессуаль законнары белән билгеләнгән тәртиптә булу.»;

2 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда, җирле салымнар буенча недоимканы түләттерүгә өметсез дип тану, бу салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булуын раслаучы документлар булып түбәндәгеләр тора:

1) салым түләүне гамәлдән чыгаручы норматив хокукый акт турында белешмәләр (исеме, номеры, датасы);

2) недоимка суммалары, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычлар турында салым органы белешмәсе;

3) “Башкарма производство турында” 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарганда суд приставы-башкаручысы карарының күчермәләре»;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының 85 статьясындагы 3 пункты нигезендә салым органына физик затларның Гражданлык хәле актларын теркәүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан физик затның үлем фактын теркәү турында белешмәләр»;

5) мирас хокукы турында таныклык бирү турында салым органы белешмәсе.».

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы штп, Совет ур. (МСУ бинасы);

ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы штп, К.Маркс ур.105 йорт,(китапханә бинасы) Шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы В. П. Сороковнин